РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ГЛАВА КОРСАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
село Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: Korsab.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.10.2024

КАРАР
№5п

**Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Сүлә торак пункты гражданнарының үзара салым акчаларыннан файдалану турында җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. 2024 елның 11 ноябрендә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Сүлә торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә:ТР, Саба районы, Сүлә авылы, Үзәк урам, 39 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Сүлә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Сүлә торак пунктында балалар мәйданчыгын кору, янәшәдәге территорияне төзекләндерү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны "Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.Р. Гыймадиев